ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 гыйнварындагы 74 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә Югары Ослан муниципаль районында 1-нче кушымта һәм 2-нче кушымта нигезендә 5701,31 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Башкаручы Г.Ф. Камалетдинова

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018нче
елның __ гыйнварыннан _____
номерлы карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районында 2018нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 143,50 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2898,09 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 820,31 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1839,41 |
| Барлыгы | 5701,31 |

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018нче
елның __ гыйнварыннан _____
номерлы карарына
2 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районында 2018нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 143,50 |
| 2. Тәнне төрү | 533 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2365,09 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 820,31 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1839,41 |
| Барлыгы | 5701,31 |